Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе



# Яңа көн

Сентябрь 2018 № 1




*Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар! Алда – чираттагы уку елы. Әлеге уку елында без моңа кадәр алган белемнәрне ныгытырбыз, алар янына яңаларын кушарбыз. Җәен ял итеп килгән, бакчаларда эшләп тагын да күбрәк көч туплаган кулларыбыз яңа һөнәрләр үзләштерергә әзер. Башларыбыз саф, күзләребез яңа көнгә елмаеп карый. Димәк, без Белем иленең ишекләрен киң итеп ачып керергә әзер. Бәйрәм белән сезне, дуслар!*

## *Бу санда*


“Акчарлак”, “Дулкын” лагерьлары

Җәйге истәлекләр, яңалыклар

Туган көнең белән, ТВБ!








Олы бәйрәм бүген бездә, Ул
беренче сентябрь.
Шатлык балкый йөзләрдә,
Бүген син дә, мин дә бер.

Беренче сентябрь – минем
Бәхет – шатлыклы көнем.
Сагынып белем учагын Мин
кабат сиңа килдем.

# "Акчарлак", "Дулкын" лагерьлары

*Быел җәй районда унтугыз мәктәптә җәйге сәламәтләндерү лагерьлары оештырылды. Аларда барлыгы 600 бала ял итте.*

*Безнең мәктәп базасында урнашкан «Акчарлак»лагеры укучыларның яраткан ял урынына әверелде. Ул быел 40баланы кабул итте. Шулай ук «Дулкын» хезмәт лагеры уңышлы эшләде, балалар бу лагерьда мәктәп тәҗрибә участогында чыныгу алдылар.*









# Җәйге истәлекләр

*Җәйге чорда мәктәбебез укучылары төрле лагерьларда ял иттеләр. Хөснетдинова Ризилә, Ахметшина Әлфинә, Сибгатуллина Ләйсәнә, Миннигалеев Рәдиф, Камалова Эльвира, Сибгатуллин Рифат “Сәләт” лагерында, Камалова Эльвира – “Юнармия”, Альмиев Рәсим, Закиров Ильшат – “Надежда” лагерьларында ял итеп кайттылар.*






# Яңалыклар

20 августтан фән укытучыларының август киңәшмәләре башланып китте.

Киңәшмәләрдә районыбыз мәктәпләре мөгаллимнәре укыту системасындагы яңалыкларны өйрәнделәр, яңа ФГОСка күчү шартларында инновацияләр турында фикер алыштылар, алдагы эшчәнлекне оештыру планнарын расладылар




28 август көнне Балык бистәсе муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе булып үтте. Бу бәйрәмгә безнең мәктәп укытучылары бик яхшы әзерләнделәр, методик эшләнмәләр күргәзмәсе әзерләделәр.

**2017-2018 уку елында 11 сыйныфны 5 укучы бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, өлгергәнлек аттестатын алдылар. Үзләре теләгән уку йортларына укырга керделәр.**



Сафиуллина Алсина – КГМУ



Ибрагимова Диләрә – ФГБОУ ВО “Казанский гос. Аграрный университет”



Сибгатуллин Данияр – «Лаишевский технико-экономический техникум»



Салахова Энҗе – КМК



Сибгатуллина Айзиля – КНИТУ

***Мәктәбебез укытучылар коллективы “Кама” агрофирмасы өчен терлек азыгы хәзерләүдә катнаштылар***



# Туган көнең белән, ТВБ!



15 сентябрь – Татарстан варислар берлегенең(ТВБ) туган көне,Татарстан варислары берлегенә 28 яшь тула. ТВБ 1990 елда барлыкка килә. Казанның “Кояшлы” пионер лагеренда республика пионер оешмасының 26 слеты делегатлары яңа балалар оешмасы – Татарстан варислар берлеген төзү турында белдерә. Бу берлек, әлбәттә, буш урында барлыкка килми. Аның нигезендә Татарстан пионер оешмасының купьеллык эшчәнлеге, данлы үткәне ята.




Безнең авылда пионер оешмасы 1932 елда төзелә. Аның беренче пионерлары Валиев Хәбибулла, Шәвәлиева Маһикамал, Булатова Гайшә, Садыков Зыялар була. 50 елларда пионер дружинасы Ульяна Громова исемен йөртә. Ә 1962 елдан ул Ю.А.Гагарин исемен йөртә башлый.Ул чор пионер отрядлары герой – пионерлар исемнәрен йөрткән. Пионер оешмабызның беренче җитәкчеләре Садыйкова Нажия, Шакирова Мәрьям, Хайрутдинова Мәрьям, Сөләйманова Сәгадәт, Абдуллина Галия. Соңгы елларда өлкән пионервожатый булып озак вакыт Ахметова Рәйсә апа һәм Билялова Халисә апа эшләде.

Дуслар! Уртак якты бәйрәмебез котлы булсын! Һәрвакытта да иҗади эшләр белән янып яшик, нәни дусларыбызга игътибарлы,өлкәннәргә ихтирамлы булыйк, “Көн саен игелек кыл!” дигән девизыбызны тормышка ашырыйк!

Бу без – бүгенге көн варислары.

